**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

19.05.2016 Яр Чаллы № 1717

«Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре,
спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан муниципаль
хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын
раслау турында» Район Башкарма комитеты җитәкчесенең
2014 елның 16 апрелендәге 1529 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1.«Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре,спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Район Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 16 апрелендәге 1529 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта нигезендә).

2.Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны яшьләр эшләре,спорт һәм туризм бүлеге башлыгы И.Р. Гәрәевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев